## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең Имәнле-Бортас авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

26 нче ноябрь 2021 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 23 нче ноябрендә 10 сәгатьтә, 2021 елның 26 нче ноябрендә 10 сәгатьтә этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Имәнле-Бортас авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре;
- Имәнле-Бортас авылы территориясен чабу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.

Экономия барлыкка килгән очракта,аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 106 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -62, бу 58,5 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 62 катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең Имәнле-Бортас авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2.«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Имәнле-Бортас авылы территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сумм күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре;
- Имәнле-Бортас авылы территориясен чабу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.

Экономия барлыкка килгән очракта,аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны мәгъүлүмат стендларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгъүлүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Кече Мәми авыл җирлеге Башлыгы Е.Н.Алексеева